| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ЛЕНИНОГОРСКИЙ<br>МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН» | | «ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14. 11. 2022 г.Лениногорск № 1155

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2020 елның 2 июнендәге 658 номерлы карары белән расланган Лениногорск муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыру турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 24 сентябрендәге 371-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Россия Федерациясендә мәҗбүри таләпләр турында»Федераль законның 1 статьясы нигезендә, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2020 елның 2 июнендәге 658 номерлы карары белән расланган Лениногорск муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыру турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

4.11 пунктны түбәндәге редакцияд бәян итәргә:

«4.11. Мәктәпкәчә белем бирүнең белем бирү программалары мәктәпкәчә белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандарты һәм тиешле федераль мәктәпкәчә белем бирү программасы нигезендә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма тарафыннан эшләнә һәм раслана. Мәгариф оешмалары тарафыннан эшләнгән белем бирү программаларының эчтәлеге һәм

планлаштырылган нәтиҗәләре федераль мәктәпкәчә белем бирү программасының тиешле эчтәлегеннән һәм планлаштырылган нәтиҗәләреннән түбән булмаска тиеш.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бстырып чыгарырга һәм «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Лениногорск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче З. Г. Михайлова

Л.М. Галимова
5-17-41